# Һади Такташ

## (1901-1931)

***«Мин яралдым серле моңнарым белән бар дөньяны еглатырга.***

***Әйе, миндә көчле Байроннар җаны»***

Ак каенга асылып менгән кебек,

Мин тормышта һаман яктыга,

Югарыга табан юл алдым.


Менгән саен, җирнең матурлыгын,

Яктылыгын күбрәк күрәлдем.



## Такташның әнисе Шәмсениса


*Рәхмәт, әнкәй, сиңа,*
*Ярый әле мине тапкансың,*
*Озын төннәр буе йокламыйча,*
*Җырлар җырлый-җырлый*
*баккансың*



*Әнисе Шәмсениса укый-яза белгән, оста сүзле, киң табигатьле, мөлаем хатын-кыз булган.*

## Такташның әтисе Хәйрулла

*Еллар үтте,*
*Менә хәзер инде,*
*Әткәй, килеп миңа карагыз,*
*Шагыйрь булды ата казлар кыйнап,*
*Шалкан урлап йөргән балагыз!..*



*Әтисе Хәйрулла урта хәлле крестьян булган, гарәп-фарсы телләрен яхшы белгән, халык арасында туры сүзле булуы белән танылган.*

*Балачак дусты Мокамайга багышлап, Һади 7 яшендә мондый җыр чыгарган була:*

Дыр-дыр, дырабан,
Мокамай күкәй урлаган;
Әйшә түтәй тоткан,
Каравылын кычкырткан!

Еллар уза, Һади Такташ даһи шагыйрь була. Мокамай да Мөхәммәтҗан булып үсеп җитә. Такташ дустының фаҗигале язмышын сурәтләп, “Мокамай” шигырен яза:

*Син адаштың,*
*Ләкин син яхшы идең,*
*Синең яхшы иде күңелең,*
*Тик белмәдең тормыш баткагыннан*
*Ялгыз чыгу мөмкин түгелен...*

# *АНА -Такташның яраткан образы*

**Ана –**


**Бөек исем,**

**Нәрсә җитә ана булуга;**

**Хатыннарның бөтен матурлыгы,**

**Бөтен күрке ана булуда.**

*“Мәхәббәт тәүбәсе”*



# Мәхәббәт җырчысы


Мәхәббәт – ул үзе иске нәрсә,

Ләкин һәрбер йөрәк аны яңарта.

Тиле яшьлек ярты гомерен бирә

Аның хисе белән янарга.






Такташның беренче хатыны
Гөлчәһрә Хәмзина



Такташның икенче хатыны
Гөлчирә Такташева-Мансурова



Такташның улы Рафаил Такташ – дәрәҗәле академик, профессор, сәнгать белгече. Ташкентта яши. Байтак кына милләт рәссамнары турында монографияләр язган. Үзе өчен шигырьләр дә иҗат иткән.



Такташның улы Аван Такташ фотога төшерү белән мавыккан. Озак еллар гәзитнең урыннарда йөрүче фотографы булып эшли.

# Такташ - бунтарь шагыйрь

Килер кешеләр

Күреп шул җырларны әйтер иде:

- Кара, чыннан да,


“Чабаталы даһи” – усал бунтарь

Җырлап үткән икән моннан да...

**Шагыйрь үлгәч**
**Үләрмен дә**
**Онытырлар, дип,**
**Юкка гына, йөрәк, янасың,**
**Тамбов урманнары сагыныр әле**
**Үзе үстергән бунтарь баласын!**
**Һ. Такташ**




**Шагыйрь яшәгән йортка урнаштырылган мемориаль такта.**




**Һади Такташ 1931 елның 8 декабрендә Казанда вафат була һәм Максим Горький исемендәге Үзәк культура һәм ял паркындагы зиратта җирләнә.**

*“Шагыйрь! Кем ул? Шагыйрь – шигырь язучы гына түгел ул, шагыйрь – үзе шигырь ул. Шагыйрь дигән сүзне әйтү белән, күңел күзе алдына Тукайлар, Есениннар килеп баса. Такташ шундыйларның берсе иде.*

*Такташ – шигырь иде ул...”*

*Х.Туфан*